КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 июль г.Казань № 548

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 сентябрь, 823 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2021 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2021 ел, 23 апрель, 275 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына, 2.6 нчы пунктның уникенче – унбишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

«алучының яки аның гаилә әгъзаларының кимендә алты ай эш эзләүче эшсез статусы булу;

алучы яки аның гаилә әгъзалары өч яше тулганга кадәр бала, яки 18 яшькә кадәрге инвалид бала, яки балачактан I төркем инвалиды, яки I төркем инвалиды, яки дәвалау учреждениесенең бәяләмәсе буенча чит кешенең даими каравына мохтаҗ йә 80 яше тулган карт кеше карауны гамәлгә ашыру;

алучы яки аның 23 яшьтән кечерәк гаилә әгъзалары гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында йә югары белем бирүче мәгариф оешмасында көндезге уку формасы буенча уку һәм стипендия алмау;

алучы яки аның гаилә әгъзалары 3 айдан артык дәвалануда булу, шуңа күрә хезмәт эшчәнлеген вакытлыча башкара алмау;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин